**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 16 июль № 520

г. Казань

Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 596 – 601, 606 нчы указларын тормышка ашыру һәм аларны алга таба үтәү буенча бурычлар турында

Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 596 – 601, 606 нчы указларында билгеләнгән бурычларны Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан алга таба тормышка ашыруны тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

2015 елга тармак «юл карталарында» билгеләнгән максатчан күрсәткечләрне һәм чараларны үтәүне тәэмин итәргә;

дәүләт оешмаларының һәм муниципаль оешмаларның эш нәтиҗәлелеген бәяләү буенча бәйсез системаны камилләштерү эшен дәвам иттерергә.

2. Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына:

җирле үзидарә органнары белән берлектә, күпфункцияле үзәкләрнең эшчәнлекләрен читтән торып башкара торган эш урыннары булдыру эшләрен тәгәлләүне, күрсәтелә торган хезмәтләр, шул исәптән «тормыш хәлләре» буенча хезмәтләр исемлеген киңәйтүне тәэмин итәргә;

муниципаль актларга карата җайга салу йогынтысын бәяләү институтын кертүне методик тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

ачык хисаплылык формаларын үз вакытында актуальләштерүне;

күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең сыйфатын күтәрү.

4. Федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр сыйфатын күтәрүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

5. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына:

Татарстан Республикасында Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 596 – 601, 606 нчы указларында билгеләнгән чараларны тормышка ашыруны мәгълүмати тәэмин итү эшен дәвам иттерергә;

сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыруга һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында 2015 елда Йөрәк-кан тамырлары авыруларына каршы көрәшү елын уздыру турында» 2015 елның 7 мартындагы ПУ-261 номерлы Указын тормышка ашыруга юнәлдерелгән чараларны мәгълүмати яктыртуны оештыру эшен көчәйтергә.

6. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

муниципаль милектә булган коммуналь өлкә объектларын концессиягә тапшыру эшен активлаштыруны;

федераль законнар таләпләре нигезендә, муниципаль берәмлекләрнең коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программаларын эшләүне төгәлләүне. Коммуналь инфраструктура объектларын паспортлаштыруны һәм әлеге мәгълүматны, соңгы 5 елда аларны төзүгә, төзекләндерүгә һәм капиталь ремонтлауга чыгымнарның күләмнәрен күрсәтеп, гамәлдәге электрон мәгълүматлар базасына кертүне тәэмин итәргә;

квартал саен Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына эшләнгән эш турында мәгълүмат кертүне;

дарулар белән тәэмин итү өлешендә социаль хезмәтләр җыелмасының саклануы турында халыкка аңлату эшләре үткәрүне, алга таба аларны үтәү турында Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына хисап кертеп тәэмин итүне.

7. Әлеге карарның үтәлеше өчен җаваплы хакимият органнарына квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 5 сенә кадәр, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тиешле мәгълүмат җибәрергә.

8. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 596 – 601, 606 нчы указларын тормышка ашыру һәм аларны алга таба үтәү буенча бурычлар турында» 2014 ел, 14 июль, 488 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

9. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы указлары үтәлешен оештыру буенча республика эш төркеме җитәкчесе А.В.Песошинга һәм Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\520.docx